ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык т.юл.рзд.пос. торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

06 декабрь 2021 ел № 1

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык т.юл.рзд.пос. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

1) контейнер мәйданчыкларын ремонтлау һәм коймалау
2) зиратны төзекләндерү
3) гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру
4) Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү
5) су бүлү һәм су белән тәэмин итү коеларын ремонтлау өчен

үтәү буенча юллау белән килешәсезме?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча этаплап, 2021 елның 3 декабрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 3 декабрендә 13 сәгать 00 минутта һәм 2021 елның 3 декабрендә 16 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1409 (бер мең дүртйөз тугыз) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 733 (җидейөз утыз өч) кеше, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 733 (җидейөз утыз өч) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Коркачык т.юл.рзд.пос. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Коркачык т.юл.рзд.пос. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

1) контейнер мәйданчыкларын ремонтлау һәм коймалау
2) зиратны төзекләндерү
3) гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру
4) Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү
5) су бүлү һәм су белән тәэмин итү коеларын ремонтлау өчен.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Коркачык авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Салихҗанов